**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2017 ел, 7 февраль № 64

г. Казань

2017 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасының төп чаралар планын һәм 2017 елга Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарә органнарын, көчләрен әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләрне раслау турында

Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарә органнарын, көчләрен әзерләү дәрәҗәсен алга таба күтәрү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2017 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасының төп чаралар планын (алга таба – План);

2017 елга Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарә органнарын, көчләрен әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләрне.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына:

Планның үтәлешен тәэмин итү чараларын күрергә;

2017 елга Татарстан Республикасы министрлыкларының, ведомстволарының гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге төп чаралар планнарын эшләргә һәм гамәлгә кертергә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башкарма комитетларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Планның үтәлешен тәэмин итү чараларын күрүне;

2017 елга гражданнар оборонасы, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасы һәм җирле дәрәҗәдәге гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарә органнарын һәм көчләрен әзерләү буенча тиешле оештыру-методик күрсәтмәләр, шулай ук гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм Татарстан Республикасы шәһәр округларының һәм муниципаль районнарының су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге төп чаралар планнарын эшләүне һәм билгеләнгән тәртиптә гамәлгә кертүне.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасының төп чаралар планын һәм 2016 елга Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарә органнарын, көчләрен әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2016 ел, 11 февраль, 88 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\64.docx